# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Ковали торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15 октябрь 2020 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 16 сәгать 00 минутта 2020 елның 15 октябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

1. Берновые Ковали авылында сууткәргечне ремонтлау, шул исәптән әлеге максатлар өчен материаллар сатып алу;
2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

«ӘЙЕ» « КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **33** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **20** кеше катнашты, бу **60,61%** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **20** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

- Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Ковали авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
- 2021 елда үзара салым акчаларын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә Берновые Ковали авылында даими яшәүче һәр балигъ булган, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2000,00 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

3.1. Берновые Ковали авылында сууткәргечне ремонтлау, шул исәптән әлеге максатлар өчен материаллар сатып алу;

3.2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

4. Әлеге карарны Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырарга.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче И.М.Фатхуллин